ГЛАВА БАЙРЯКИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ЮТАЗИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Ютазинская, д.14А,
с.Байряка, 423963

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БӘЙРӘКӘ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
Ютазы урамы, 14А йорт,
Бәйрәкә авылы, 423963

Тел.:(85593) 2-44-12, факс: 2-44-13, e-mail: Bay.Utz@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**№ 15** **20 октябрь 2023 ел**

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы
Бәйрәкә авыл җирлегенең Бәйрәкә торак пунктында
гражданнарның үзара салым чараларын кертү һәм
куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

2003 елның 06 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләренә, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсенә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Бәйрәкә авыл җирлеге Уставының 14 маддәсенә ярашлы, Ютазы муниципаль районы "Бәйрәкә авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге башлыгы
КАРАР ИТТЕ:

1. 2023 елның 2 ноябрендә 14.00 сәгатькә Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Бәйрәкә торак пунктында Бәйрәкә авылында теркәлгән һәм Абдуллин, Авангард, Вахитов, Кооперация, Минһаҗев урамнары буенча сайлау хокукына ия гражданнар өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын билгеләргә.

2. 2023 елның 3 ноябрендә 10.00 сәгатькә Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Бәйрәкә торак пунктында Бәйрәкә авылында теркәлгән һәм октябрь, Пушкин, Сельхозтехника, Татарстан урамнары буенча сайлау хокукына ия гражданнар өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын билгеләргә.

1. 2023 елның 4 ноябрендә 14.00 сәгатькә Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Бәйрәкә торак пунктында Бәйрәкә авылында теркәлгән һәм Тукай, Ютазы, 1 Май, 8 Март урамнары буенча сайлау хокукына ия гражданнар өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының өченче этабын билгеләргә.

4. Түбәндәгеләрне билгеләргә:

- Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Бәйрәкә торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын оештыручы - Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Бәйрәкә авыл җирлеге башкарма комитеты;

- гражданнар җыенының беренче этабын үткәрү вакыты 2023 елның 02 ноябре 14.00 сәгатьтән 15.00 сәгатькә кадәр;

- гражданнар җыенының икенче этабын үткәрү вакыты 2023 елның 03 ноябре 10.00 сәгатьтән 15.00 сәгатькә кадәр;

- гражданнар җыенының өченч этабын үткәрү вакыты 2023 елның 04 ноябре 14.00 сәгатьтән 15.00 сәгатькә кадәр;

- уздыру урыны – Бәйрәкә ав., Октябрь урамы, 1А йорт, авыл мәдәният йорты;

5. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Бәйрәкә авыл җирлеге башкарма комитетына түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

- 2023 елның 26 октябреннән дә соңга калмыйча гражданнарга Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Бәйрәкә авыл җирлеге Башкарма комитетында Бәйрәкә авылы, Ютазы урамы, 14А йорт адресы буенча гражданнар җыены карарына чыгарыла торган материаллар белән танышу хокукын тәэмин итәргә;

- сайлау хокукына ия булган Бәйрәкә торак пунктында яшәүчеләрнең исемлеген төзергә;

- гражданнар җыенына мәгълүмати материаллар әзерләргә;

- Бәйрәкә торак пункты халкына массакүләм мәгълүмат чараларында һәм башка ысуллар белән гражданнар җыены турында хәбәр итәргә.

5. Рекомендовать Исполнительному комитету Байрякинского сельского поселения Ютазинского муниципального района Республики Татарстан:

- не позднее 26 октября 2023 года обеспечить гражданам право на ознакомление с материалами, выносимыми на решение схода граждан в Исполнительном комитете Байрякинского сельского поселения Ютазинского муниципального района Республики Татарстан по адресу: с.Байряка, ул.Ютазинская, д.14А;

- составить списки жителей населенного пункта Байряка, обладающих избирательным правом;

- подготовить информационные материалы к сходу граждан;

- оповестить население населенного пункта Байряка в средствах массовой информации и иными способами о сходе граждан.

6. Гражданнар җыенына чыгарыла торган түбәндәге мәсьәләне расларга:

"Сез 2024 елда Бәйрәкә авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган гражданга, 1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышында катнашучылардан һәм ветераннардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол калган хатыннарыннан, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан тыш, 600 (алты йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә ризамы; әлеге түләүне бер тапкырга киметеп 2 төркем инвалидлар өчен 300 (өч йөз) сум күләмендә билгеләргә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

1. Торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:

- грейдерлаштыру, юлларны кардан чистарту (ягулык-майлау материалларын сатып алу, тракторист һәм техника арендалау, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү);

- Бәйрәкә авылында Вахитов урамы буенча юл - урам челтәрен норматив хәлгә китерү (смета буенча юл төзү: вак таш, асфальт сатып алу, нигез әзерләү, ташу, салу, эш өчен түләү);

2. Торак пункт территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау, аларның үтәлешен контрольдә тоту, күрсәтелгән кагыйдәләргә ярашлы рәвештә торак пункт территориясен төзекләндерүне оештыру:

- Бәйрәкә авылында урам яктырту объектларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (лампалар, энергия саклаучы яктырткычлар, электр товарлары сатып алу һәм урнаштыру, агымдагы ремонт һәм урам яктыртуына хезмәт күрсәтү);

халыкның күпләп ял итү урыннарын (парк) төзү һәм аларга якын территорияләрне төзекләндерү;

- Бәйрәкә авылында су белән тәэмин итү челтәрләрен ремонтлау (материаллар, җиһазлар сатып алу, өзеклекләрне бетерү, торбаларны алыштыру, килешү буенча эшләр өчен түләү).

3. Ритуаль хезмәтләр оештыру һәм җирләү урыннарын карап тоту:

- Бәйрәкә авылындагы зират территориясендә карт, кипкән агачларны кисү, агачларны химик эшкәртү (химия препаратлары сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү);

« ӘЙЕ » « ЮК »

4. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында түбәндәге электрон адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

5. Әлеге карар басылып чыккан көннән үз көченә керә.

Бәйрәкә авыл җирлеге башлыгы А.О. Әхмәтшина